ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**"Физик культура һәм спорт турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Физик культура һәм спорт турында" 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"18 статья. **Спортчының яисә спорт әзерлеге узучы затның физкультура-спорт оешмасына яисә мәгариф оешмасына каравы**

1. Спортчының физкультура-спорт оешмасына каравы спортчы һәм физкультура-спорт оешмасы арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе нигезендә һәм (яисә) спортчының, оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый-дәүләти оешма булган физкультура-спорт оешмасында әгъза булуы нигезендә билгеләнә.

2. Спорт әзерлеге узучы затның спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган физкультура-спорт оешмасына каравы Россия Федерациясе бюджет системасы тиешле бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән дәүләт (муниципаль) йөкләмәсе яисә физик һәм (яисә) юридик затлар акчалары исәбеннән спорт әзерлеге буенча хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә спорт әзерлеге

узу өчен затны мондый оешмага кабул итү турындагы эш йөртү акты нигезендә билгеләнә.

3. Спортчы яисә спорт әзерлеге узучы зат мәгариф оешмасына кабул ителгән һәм спортчы белән әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән шартнамә төзелмәгән булса, спорт әзерлеге узучы затка карата әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән эш йөртү акты булмаса, спортчының яисә спорт әзерлеге узучы затның мәгариф оешмасына каравы затны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмасына укырга кабул итү турындагы эш йөртү акты нигезендә билгеләнә.";

3) 28 статьяның 2 өлешендә ", шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының үзләренә физик культура һәм спорт өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда катнашуларына бәйле бүтән чараларны тәэмин итәргә" сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 6 марты
№ 8-ТРЗ